**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«20» 03 2024 ел Яр Чаллы № 724

Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, 2024 елга Тукай муниципаль районы буенча торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак биналар милекчеләре өчен торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясы 4 өлеше нигезендә, «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар, шулай ук мондый түләүне үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча карар кабул итмәгән торак биналар милекчеләр өчен торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында методик рекомендацияләрне раслау хакында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы карарының 4.1 пунктына таянып, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, 2024 елга Тукай муниципаль районы буенча торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак биналар милекчеләре өчен торак бинаны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 2024 елның 1 январеннан 2024 елның 31 декабренә кадәрге чорга 6 процент күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин